

**Ибраева Суфия Ибраһимовна**

***Суфия апа 1928 елда Югары Кибәхуҗа авылында туган. Әтисе Ибраһим абый, әнисе Мәгмүзә апа.Ул тормышны әтисе Ибраһим абый сугышка киткәннән соң тарта башлый. Авылдан 25 км ераклыкта урнашкан Арча станциясеннән чәчүлек симәнә, ипи алып кайтулар үзе бер "әҗәл " иде дип искә ала Суфия апа. Сугыш чорында ул хуҗалык эшләрендә бик тырышып хезмәт итә. Сугышчыларга бияләй бәйләп җибәрү, сугышка бәрәңге киптереп җибәрүләр болар барысыда безнең баштан үтте дип искә ала Суфия апа. Ләкин алар тормыш сынауларына бирешмиләр.***

***Тормыш дәвам итә.1945 елда сугыш тәмамлангач әтисе Ибраһим абый туган якларына әйләнеп кайта. Шуннан соң гына тормыш йөге Суфия апага бераз җиңеләя. Ул колхозда төрле тармакларда тырышып эшли. Гомеренең 20 елын фельдшерлык –акушерлык пунктында санитарка булып эшләп лаеклы ялга чыга.***

***Суфия апа бүген берүзе генә тыныч гомер кичерә. Булышырга килгән "тимурчыларга" чын күңелдән рәхмәт әйтеп кала.***



**БөекВатан сугышы ветераны**
**Низамов Фәйзерахман Фәйзи улы**

***Фәйзи абый 1923 елда Югары Кибәхуҗа авылында туган. 4 класс белем алган. Аннан соң үзенең тормыш юлын хезмәт белән бәйли Фәйзи абый. Колхозда 10 ел буе бригадир булып эшли. Аннан соң аны амбар бригадиры итеп күчерәләр. Шуннан соң ул төзүчеләр бригадасы бригадиры булып эшли башлый. 1941 елның башында Чистайдагы ФЗӨ гә җибәрелә. Анда урманчылык эшенә өйрәгән чакта Бөек Ватан сугышы башлана. Авылга кайтып күптә үтми аны армия сафларына алалар.1942 елда ул сугышка керә. Немецларны ул Украина фронтына кушылып сугышкан вакытта каты яралана. 6 ай госпитальдә ята . Аннан соң аны туган якларына кайтарып җибәрәләр.***

***Сугыштан соңгы чорда ул кул кушырып өйдә утырмый.Туган колхозында тырышып хезмәт куя. Колхоз бригадиры булып озка еллар эшли. Шул елларда колхозларга фермалар төзиләр. Хуҗалыкларны аякка бастыруда Фәйзи абый үзеннән зур өлеш кертә. Үзенең гомерлек һөнәренә дә Фәйз абый бик теләп өйрәнә. Ул балта остасы булып китә. Тормыш җайга бара. 4 ел буе күзәтеп йөргән авылның иң акыллы, иң уңган кызы Асия апа белән 1948 елда гаилә корып җибәрәләр. 5 кыз бала, 1 ир бала тәрбияләп үстереп аларны тормышка чыгаралар. “Авылда минем кулым тимәгән бер генә йортта юк” – дип искә ала Фәйзи абый. Чөнки ул һәр кешегә йорт-җир булдыруда бик теләп булыша. Алар бүген бик рәхәтләнеп тормышка шөкер итеп кенә яши бирәләр. Булышырга килгән “тимурчыларга” зур рәхмәтләр әйтеп , аларны озатып калалар.***

***Фәйзи бабай бүген авылыбызның иң мөхтәрәм кешесе. Ул сугыштагы батырлыклары һәм бик күп орден, медаль белән бүләкләнгән сугыш ветераны. Укучылар белән әңгәмәләр корып сугыш хатирәләрен яңартып искә төшереп торалар.***



**Галимарданова Оркыя Галимәрдән кызы.**

***Оркыя апа 1926 елда Югары Кибәхуҗа авылында туган . Ул 1 класс кына укып калган. Гаиләдә 4 бала үскәннәр. “Абыем сугышка китте, аннан исән-сау әйләнеп кайтты. Гомерем буе колхозда эшләдем . Шәмәрдән ягында урман кискәндә, Курса авылы янында поездлардан сикереп төшеп кала идек. Чистай ягына сал агызырга бардык. Үзебезнең авылның Һәдия дә бар иде, баракта тордык, аякта чабата, гомер буе рәхәт күрмәдек”- дип искә ала Оркыя апа. Җәй көне көн озын урак уралар, чүп утыйлар.Аннан төн буе печән, салам эскертләү дә алар җилкәсендә була. Явлаштау урманына да барып урман кисүләр, солы симәнәсен Шармаш авылыннан алып кайту, шуннан соң бу симәнәне 25 км ераклыкта урнашкан Арча станциясеннән алаштырып кайтулар аларның яшьлек чорларына туры килә.Яз көннәре язгы чәчүдә плугар булып эшләргә туры килә. “Шулай бер вакыт Гыйлаҗи абый белән эшләгәндә трактор плугы бәреп, 1 елдан артык авырып яттым” –дип искә ала автор.Сугыштан соң тормышка чыга. Ире Миннислам белән тату гомер кичерәләр . Оркыя апа бүген берүзе яши. Булышырга килгән укучыларга бик рәхмхтләр укып кала. “Без сугыш әчесен күреп тә исән калык, еллар имин булып исән-сау гына яшәргә язсын”- ди ул.***



**Низамова Халисә Низам кызы**

***Халисә апа 1916 елда Югары Кибәхуҗа авылында туган. Семьяда 6 бала үскәннәр. Сугыш башлангач 3 абыйсы сугышка китә. Барысыда исән-сау туган җирләренә әйләнеп кайталар.***
***“Үзем сугыш вакытында колхозда эшләдем. Йөргән егетемне Армиягә озаттым, аннары сугыш башланды. 10 ел буе көтеп тә кавыша алдмадык. Ул кайтканда мин олыгаеп килә идем. Шуннан соң тормышка чыкмадым. Әнием белән икәү яшәдек. Сугыш чорында Явлаштау, Леспромхоз, Шәмәрдән урманнарын кистек. Мин гомер буе колхозда урак уру, печән-борчак чабу, траншея казу, нинди эш бар барысын эшләдек”- дип искә ала Халисә апа. Шул елларда алабута ашарга, кычыткан, черек бәрәңге ашарга туры килә аларга.***
***“Сугыш безне парлылыктан мәхрүм итте, сыңар катан булып яшәдем. Кеше көлдермәдем аллага шөкер. Ким хур булмадым. Кеше сөйли М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” романында без төп геройлар диләр. Үзем укый белмәгәч әйтә алмыйм.” – дип искә ала Халисә апа үзенең үткән тормыш юлын.***
***Укучылар аңа һәрдаим булышып торалар.Ул аларны бик ярата. Рәхмәтләр әйтеп озатып кала.***
***“Исән сау яшәгез,минем тормышны-сезгә күрергә язмасын.”- дип изге теләкләр тели Халисә апа.***

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы**
**Югары Кибәхуҗа урта мәктәбе**
**Республика Татарстан Тюлячинский муниципальный район**
**Верхнекибякозинская средняя школа**

**Тема:** *“Безнең -- Тимурчылар”*
*“Наши Тимуровцы”*

Җитәкче:
Гинатуллина Гөлчәчәк Наил кызы
педагог-оештыручы

Руководитель:
Гинатуллина Гульчачак Наилевна
педагог – организатор

**Конкурсның исеме:**
“Тимучылар хәрәкәте - бүген”
**Название конкурса:**
“Тимуровское движение  сегодня”



5 сыйныфлар – Ибраһимова Суфия , 6 сыйныфлар – Хасанова Мәрьямбикә , 7 сыйныфлар - Низамова Халисә әбиләргә булышалар. Алар атнага 2 тапкыр : сишәмбе, җомга көннәрендә баралар. Укучылар : су китерү, кибеттән кирәк әйберне алып кайту, идән себерү, тузан сөртү, утын кисү, яру, кертеп урнаштыру кебек эшләрне теләп башкаралар. Үзләре булыша торган әби-бабайларны укучылар бәйрәмнәрдә аларга бүләкләр дә әзерлиләр.



Бу эшләрнең башында мәктәбебезнең педагог –оештыручысы Гинатуллина Гөлчәчәк Наил кызы маяк булып тора. “Тимур штабы укучылары ” үзләре ярдәм итә торган өлкәннәрнең тормышларын да бик теләп өйрәнәләр.

Киләчәктә “Тимурчылар” бу эшләрен киңрәк масштабта алып барырга исәплиләр.



***Хәсәнова Мәрьям Хәсән кызы***

***Мәрьям апа 1923 елда Теләче районы Югары Кибәхуҗа авылында Асылбикә апа белән Хәсән абыйның 2 баласы булып дөньяга килә. Кибәхуҗада 4 класс белем алганнан соң үзенең тормыш юлын колхоз эше белән бәйли. “Авылда фермада бик зур үгез бар иде, шуны җигеп басудан салам, печән ташый идек. Аякта чабата, өстә кырык җирдән ямаулы күлмәк-ыштан иде”- дип искә ала Мәрьям апа. Тормышлар авыр булса да, басудан черек бәрәңге җыеп көлчә ашасаларда, кычыткан белән алабута ашасаларда, аларда яшьлек дәрте ташып торган. “Тиз генә эшне бетерер идек тә, су буена кичке уенга төшә торган идек. Анда җырлап, уенннар уйнап авыр вакытлар онытыла торган иде” ди автор.***

***Мәрьям апа тормышка чыккач ире Габделәхәт белән ике малай алып кайталар. Бер балалары яшьли үлеп китә. Ә бер малай бүген кайда икәнлеген ана үзе дә белми... Бу тормыш авырлыгымы яки башка сәбәпме? Бу сорауга җавап булмады...***

***Аларны тормыш туган авылдан Түбән Кама якларына илтеп ташлый. Анда алар озак еллар яшәп, ире вафат булгач Мәрьям апа туган нигезенә кабат кайтып төпләнә. Бүген ул җыйнак кына матур өйдә гомер итә. “Бүгенге көнгә мең шөкер ди ,пенсия вакытында килә, хөкүмәтебезгә рәхмәт”- ди ул . Булышырга килгән укучыларга да мең-мең рәхмәтләр әйтеп озатып калда. Бу олы җанлы, киң күңелле ак әбигә без дә исәнлек телибез.***